ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22 март 2024 ел № 1782

Гражданнарны аз керемле дип тану һәм аларга социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирү максатында, аларның керем күләменең һәм мөлкәт бәясенең чик кыйммәтләрен раслау турында

Гражданнарны аз керемле дип тану һәм аларга социаль наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондындагы торак урыннар бирү максатында, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Законы һәм шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Гражданнарны аз керемле дип тану һәм аларга социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирү максатында, 2024 елга гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килүче керем күләменең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең түбәндәге чик кыйммәтләрен билгеләргә:

1) гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килүче керемнең чик кыйммәте – 41 529 сум 75 тиен;

2) гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең чик кыйммәте:

- ялгыз яшәүче граждан өчен – 1 667 682 сум;
- ике кешедән торган гаилә өчен – 3 335 364 сум;
- өч кешедән торган гаилә өчен – 5 003 046 сум;
- дүрт кешедән торган гаилә өчен – 6 670 728 сум;
- биш кешедән торган гаилә өчен – 8 338 410 сум;
- алты кешедән торган гаилә өчен – 10 006 092 сум;
- җиде кешедән торган гаилә өчен – 11 673 774 сум;

- сигез кешедән торган гаилә өчен – 13 341 456 сум.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары вазыйфаларын башкаручы А.Н. Лашинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                                                 Ф.Ш. Салахов